ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь, 2015 ел № 3/4

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымын (алга таба – салым) билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

1) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек яисә терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,013 проценты күләмендә;

2) күпфатирлы йортлар урнашкан яки аларны төзү өчен сатып алынган (бирелгән) һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары урнашкан (торак фондка һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасына карамаган объектка туры килгән җир кишәрлегенә хокукка ия булу өлешеннән тыш) җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,11 проценты күләмендә;

3) шәхси торак йортлар урнашкан яки аларны төзү өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,172 проценты күләмендә;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,28 проценты күләмендә;

5) авыл хуҗалыгы җирләренә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылган җирләргә караган җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,3 проценты күләмендә;

6) гаражлар урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,4 проценты күләмендә;

7) ял итү һәм дәвалау-сәламәтләндерү объектлары урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,0 проценты күләмендә;

8) җитештерү һәм административ биналар, корылмалар, сәнәгать, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату, хәзерләү корылмалары;

портлар, су, тимер юл вокзаллары, автоюл вокзаллары, аэропортлар, аэродромнар, аэровокзаллар урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,04 проценты күләмендә;

9) автомобиль куюу урыннары урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,05 проценты күләмендә;

10) тимер юллар, автомобиль юллары, файдалы казылмаларны эшкәртү, ясалма рәвештә төзелгән эчке су юллары, причаллар, пристаньнар, тимер һәм автомобиль юлларына чиктәш полосалар, су юллары, торбаүткәргечләр, элемтәнең кабельле һәм һава линияләре һәм радиофикация линияләре, конструктив элементларны электр белән җибәрүнең һава линияләре, җир өстендәге һәм җир астындагы биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне, транспорт, энергетика һәм элемтә җайланмаларын эксплуатацияләү, карап тоту, төзү, үзгәртеп кору, үстерү өчен зарур булган корылмалар, объектлар урнаштыру; җир өстендәге корылмалар һәм спутник элемтәсе инфраструктурасы, космик эшчәнлек объектлары, хәрби объектлар урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,22 проценты күләмендә;

11) кунакханәләр һәм отельләр урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,28 проценты күләмендә;

12) сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,35 проценты күләмендә;

13) административ һәм офис биналары урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,4 проценты күләмендә;

14) башка җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 1,5 проценты күләмендә.

3. Түбән салым ставкасын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

1) шәхси базлар урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,1 проценты күләмендә;

2) шлам җыючылар урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,2 проценты күләмендә;

3) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан яки Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетыннан керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә финансланган казна учреждениеләре; эшчәнлекләре Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан яки Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетыннан фининслар белән тәэмин ителгән бюджет һәм автоном учреждениеләр урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,39 проценты күләмендә;

4) шәһәр электр транспорты объектлары урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,5 проценты күләмендә;

5) физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәт күрсәтү өчен

файдаланылган объектлар урнашкан, җир кишәрлекләренә карата кадастр хакының 0,85 проценты күләмендә, объектны эксплуатациягә кертү датасыннан кулланыла.

4. Салым салудан азат итәргә:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын, шулай ук сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан ветераннарны һәм инвалидларны;

2) I нче һәм II нче төркем инвалидлыкка ия затларны;

3) Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, шулай ук законнар нигезендә Бөек Ватан сугышында катнашучыларның социаль гарантияләре һәм өстенлекле ташламалары каралган гражданнарны;

4) 1991 елның 15 маендагы «Чернобыль АЭСындагы афәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1244-1 санлы Россия Федерациясе Законы, 1998 елның 26 ноябрендәге «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны агызу нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 175-ФЗ санлы Федераль законы һәм 2002 елның 10 январендәге «Семипалатинск полигонында атом-төш коралын сынау нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 2-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия булган физик затларны;

5) Советлар Союзы Геройларын, Россия Федерациясе Геройларын, Социалистик Хезмәт Геройларын һәм Дан, Хезмәт Даны һәм «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнарының тулы кавалерларын;

6) парклар, скверлар, шоссе, урамнар, тыкрыклар, мәйданнар, трамвай юллары, зиратлар урнашкан гомуми кулланыштагы җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан финансланучы социаль-мәдәни өлкә һәм торак объектлары төзелешенә билгеләнгән җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

8) Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы яки Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге карарлары нигезендә инновацион һәм (яисә) инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен төзелгән технопарклар (сәнәгать, индустриаль парклар) урнашкан җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

9) мунча хезмәте күрсәтү өчен файдаланылган җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан тулаем яисә өлешчә финансланучы салым түләүчеләрне;

10) күргәзмә эшчәнлеге өчен бирелгән җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

11) стадионнар урнашкан җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

12) дәүләтнеке булмаган мәктәпкәчә белем учреждениеләре өчен мәгариф объектларын төзү һәм (яки) эксплуатацияләү өчен бирелгән җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

13) берничә катлы транспорт чараларын куеп тору урыннарын төзү һәм (яки) эксплуатацияләү өчен бирелгән җир кишәрлекләре

мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне;

14) серияле җитештерүне модернизацияләү максатларында, спорт-узышу автомобильләренә тест уздыру өчен автодромлар урнашкан җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә салым түләүчеләрне.

5. Әлеге Карарның 4 пункты 1-5 пунктчалары белән каралган физик затларга ташламалар фәкать эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмаган җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә бирелә.

6. Әлеге Карарның 4 пункты 12 һәм 13 пунктчалары белән каралган ташламалар җир кишәрлегенә хокукны дәүләт теркәве көненнән алып ике елдан артмаган төзелеш чорына бирелә.

7. Әлеге Карар нигезендә салым түләүдән азат ителгән салым түләүчеләр җир кишәрлекләрен арендага (файдалануга) биргәндә, арендага (файдалануга) бирелгән мәйданнан салым алына.

8. Салым базасын киметүгә тиешле хокукны раслаучы документлар салым түләүче тарафыннан салым салу объекты дип танылган җир кишәрлеге урнашкан урын буенча салым органына узган салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр тапшырыла.

9. Җир кишәрлеге рөхсәт ителгән файдалануның бердән артык төренә ия булган очракта, салым салу максатларында, әлеге кишәрлек өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча иң зур салым ставкасы кулланыла.

10. Салым түләүчеләр – оешмалар өчен хисап чоры булып календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы санала, дип билгеләргә.

11. Салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым түләү беренче, икенче, өченче квартал узгач, үткән хисап чорыннан соң килә торган икенче айның икенче числосыннан дә соңга калмыйча, җир кишәрлегенең кадастр хакының процентлы өлешенә тиешле салым ставкасының 1/4 өлеше күләмендә аванс түләүләре рәвешендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

12. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2008 елның 21 ноябрендәге 225-227 саннарында басылган);

2) Шәһәр Советының 2009 елның 18 июнендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 41/8 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2009 елның 24 июнендәге 117-118 саннарында басылган);

3) Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 43/7 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2009 елның 28 октябрендәге 207-208 саннарында басылган);

4) Шәһәр Советының 2009 елның 23 декабрендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6

санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 44/7 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2009 елның 25 декабрендәге 247-249 саннарында басылган);

5) Шәһәр Советының 2010 елның 15 ноябрендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 4/5 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2010 елның 19 ноябрендәге 223-225 саннарында басылган);

6) Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 13/5 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2011 елның 2 сентябрендәге 94 санында басылган);

7) Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25/6 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2013 елның 11 июнендәге 44 санында басылган);

8) Шәһәр Советының 2014 елның 21 февралендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 29/8 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2014 елның 26 февралендәге 14 санында басылган);

9) Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 34/5 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2014 елның 26 ноябрендәге 88 санында басылган);

10) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» 35/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 39/10 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2015 елның 6 маендагы 32 санында басылган).

13. Әлеге Карар 2016 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртә түгел.

14. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ